# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ
# КАРАРЫ

**№2** **26.11.2021 ел**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Чемодур авыл җирлеге составына керүче
Чемодур авылында 2022 елда гражданнарның үзара
салымын кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлегендә гражданнар җыены

**Карар чыгарды:**

1. 2022елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 350,00 (өч йөз илле) сум күләмендә, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм катнашучыларының, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, бер тапкыр түләүне киметергә, аны 2 группа инвалидлар өчен 175 сум итеп билгеләргә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге оешмаларга юнәлдерергә::
- Чемодурово авылында үлән чабу, чүп-чар җыю хезмәтләре;
- Чемодурово авылындагы зиратларны коймау;
- «Сабантуй», «Авыл көне», «9 май», «өлкәннәр көне», «Яңа ел»бәйрәмнәрен үткәрүгә сувенир продукция сатып алу;;
- Трактор өчен асылмалы җиһазлар сатып алу;
- Тракторчының хезмәт хакы;
- Трактор өчен ягулык-майлау материаллары..

3. Гражданнар Җыенының әлеге карарын түбәндәге веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнашкан: http//aznakayevo.tatar.ru һәм Чемодурово авылы, Үзәк урамы , 4А йорт , Молодежная урамы, 20А адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Чемодурово авыл җирлеге башлыгы Н.Б.Котельникова